| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.01.2018 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 17** |

2018 елга Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Зеленодольск муниципаль районы Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елга түбәндәгеләрне расларга:

Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымтада бирелгән норматив чыгымнарын;

балаларга сәнгать-эстетика юнәлештәге өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә итеп төзәтү коэффициентын.

2. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Н.Нуриевага йөкләргә.

ЗМР БК җитәкче вазифаларын башкаручы А.В.Старостин

Расланган

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 10 гыйнварындагы
17 номерлы карары белән

**Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (1 елга 1 укучыга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 50957 | 59068 | 76860 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 55683 | 64454 | 83712 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 28213 | | 24536 | 58933 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 30640 | | 26713 | 64146 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 53529 | 44144 | 161039 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 58850 | 48526 | 177088 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 23410 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 25637 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 50400 | 48358 | 78311 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 55306 | 53072 | 85850 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 77640 | | 74287 | | 122709 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 84935 | | 81297 | | 134154 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 40144 | | 37262 | 37263 | 59003 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 43880 | | 40750 | 40748 | 64149 |